СОВЕТ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ

**Карар** **Решение**

№ 17-34 от «23» июля 2019 г.

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Советының 2015 елның 15 октябрендәге 4-2 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районында муниципаль хезмәт турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында

«Мәҗбүри пенсия иминияте системасында индивидуаль (шәхсиләштерелгән) исәпкә алу турында «Федераль законга һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2019 елның 1 апрелендәге 48-ФЗ номерлы Федераль закон «Дәүләт граждан хезмәте турында Татарстан Республикасы Законының 10 статьясына һәм муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексына үзгәрешләр кертү хакында» 2018 елның 13 июлендәге 50-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Советы КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Советының 2015 елның 15 октябрендәге 4-2 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районында муниципаль хезмәт турындагы Нигезләмәгә (12.11.2016 ел, № 3-12, 12.05.2017 ел, № 8-16, 26.07.2017 ел, № 4-18, 13.11.2017, №4-19, 29.06.2018 №10-27, 03.09.2018 № 8-28, 19.11.2018 № 11-29, 28.03.2019 №8-32 карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә:

1.1. 12.3 пунктның 6 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«индивидуаль (шәхсиләштерелгән) исәпкә алу системасында, шул исәптән электрон документ формасында теркәүне раслаучы документ»;

1.2 25.9 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

Конкурс үткәрү турында мәгълүмат әлеге статьяда 25.8 өлешендә каралган, , уку тәмамланганнан соң гражданнар тарафыннан алмаштырылырга тиешле муниципаль хезмәт вазыйфалары төркемнәре күрсәтелә; әлеге вазифаларга квалификация таләпләре; әлеге статьяның 25.8 өлеше нигезендә конкурска тапшырыла торган документлар исемлеге, кабул итү урыны һәм вакыты; күрсәтелгән документлар кабул ителә торган срок; конкурсны үткәрү

000075

датасы, урыны һәм тәртибе; максатчан укыту турында шартнамә төзүгә кандидатларны бәяләү һәм сайлап алу өчен кулланыла торган конкурс процедуралары; язма биремнең темасы (конкурс процедураларының конкурс комиссиясе тарафыннан кулланылучы берсе язма бирем булса), шулай ук башка мәгълүмат материаллары да булырга мөмкин.»;

1.3. 25.16 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Конкурс комиссиясе дәгъвачыларны әлеге статьяның 25.11 өлешенең 1-6 пунктларында күрсәтелгән документлар нигезендә, һәм шулай ук конкурс процедуралары нәтиҗәләре буенча бәяли. Җирле үзидарә органы карары буенча конкурс процедуралары индивидуаль әңгәмә, тест һәм (яки) язма биремне күздә тота.»

2. Әлеге карарны Мамадыш муниципаль районының http://mamadysh.tatarstan.ru рәсми сайтында, "Интернет" мәгълүмати-коммуникацион челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo. tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Мамадыш муниципаль районы Советының Регламент, законлылык, хокук тәртибе һәм депутат этикасы буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Район Башлыгы,
муниципаль район
Советы рәисе

А.П.Иванов